РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Краснокадкинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423558, Нижнекамский район,
с. Верхние Челны, ул. Молодежная, 13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кызыл Чапчак авыл жирлеге
Советы

423558, Түбән Кама районы,
Югары Чаллы авылы, Яшьләр урамы, 13

тел./факс (8555) 44-50-21, электронный адрес: Krasnokadkin.sp@tatar.ru,
сайт: www.krasnokadkinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.06.2021 ел № 12

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының 2007 елның 2 апрелендә кабул ителгән 13 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау турында» 2021 елның 29 июнендәге 36 номерлы карарын игътибарга алып, Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Кызыл Чапчак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2007 елның 2 апрелендә кабул ителгән 13 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кызыл Чапчак авыл җирлеге
башлыгы Б.В. Илдарханов